ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе хисабы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2023 ел өчен Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе хисабын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе белән берлектә фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре белән шөгыльләнә торган оешмаларга региональ салым ярдәме чаралары системасын эшләүнең максатка ярашлы булуын карарга.

2.2. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенә «Татарстан Республикасын фәнни-технологик үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру буенча проект офисы вәкаләтләре бирү мәсьәләсен карарга.

2.3. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе белән берлектә Татарстан Республикасында Фәнни-технологик үсеш елы вакыйгаларын төрле яклап яктыртуны оештырырга, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары аша фәнне һәм әһәмиятле фәнни проектларны популярлаштыруга юнәлдерелгән материаллар таратуга ярдәм итәргә.

3. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. «Татарстан Республикасын фәнни-технологик үстерү», «Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү», «Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү», «Татар халкының милли үзенчәлеген саклап калу», «Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау» һәм башка Татарстан Республикасы дәүләт программалары кысаларында фәнни-тикшеренү эшчәнлеген дәвам итәргә.

3.2. Яшь фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү эшен дәвам итәргә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетына фән өлкәсендәге законнарны гамәлгә ашыруны тикшереп тору эшен дәвам итүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы Ю.З. Камалтынов

Казан шәһәре,
2024 елның 29 марты
№ 2389-VI ДС